**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**СПАС**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**СПАССКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**КАРАР** **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**№ 861** **“04” 12 2019 ел**

**2019 елның 07 мартындагы 157 номерлы Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы башкарма комитетының карары белән расланган 2019-2023 елларга Татарстан Республикасы Спас муниципаль районында кече һәм урта эшкуарлык субъектларын үстерү программасына үзгәрешләр кертү турында**

Спас муниципаль районында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү өчен уңай шартлар тудыру максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2013 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2010 елның 21 гыйнварындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы башкарма комитеты:

**КАРАР БИРӘ:**

1. 1. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Башкарма комитетының «2019-2023 елларга Татарстан Республикасы Спас муниципаль районында кече һәм урта эшкуарлык субъектларын үстерү программасын раслау турында» 2014 елның 07 мартындагы 157 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. «Программа төп чаралары» IX бүлегендә «кече һәм урта эшкуарлык субъектлары» сүзләреннән һәм «кече эшкуарлык субъектлары» сүзләреннән соң «, шул исәптән социаль эшкуарлык» сүзләрен өстәргә.

1.2. «Программаның төп чаралары» IX бүлеге кушымта нигезендә юллар өстәргә.

2. Әлеге карарны Спас муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (htth:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны башкарма комитет җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары Р.Р. Закировага йөкләргә.

ТР Спас муниципаль районы башкарма
комитеты җитәкчесе В. А. Осокин

6 нчы таблица

# IX. ПРОГРАММАНЫҢ ТӨП ЧАРАЛАРЫ

| № п/п | Бурычның исеме | Төп чараларның исеме | Программа чараларын башкаручы | Сроклары үтәү төп чаралар | Финанслау чыганаклары |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| | Социаль эшкуарлыкны үстерү һәм аңа ярдәм итү | Түләүсез нигездә биналарны файдалануга бирү | Спас муниципаль районы Советы, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Башкарма комитеты, Болгар шәһәр Башкарма комитеты | 2019-2024 еллар | Финансламыйча |
| | | Социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларның күрсәтелгән урыннар буенча коммуналь хезмәт күрсәтүләренә түләү (Спас муниципаль районының ветераннар (пенсионерлар) җирле иҗтимагый оешмасы, Бөтенроссия инвалидлар җәмгыяте «Татарстан Республикасы инвалидлар җәмгыяте» республика иҗтимагый оешмасының Спас район оешмасы) | Спас муниципаль районы Советы, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Башкарма комитеты, Болгар шәһәр Башкарма комитеты | 2019-2024 еллар | Җирле бюджет |